# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Алга торак пунктында
2026 елда үзара салым кертү турында

**14.11.2025 ел** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 31 октябрендәге 5 номерлы “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Алга авылында 2026 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турындагы” карары нигезендә 2025 елның 14 ноябрендә 8.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә Алга авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш гражданнардан, 2026 елда үзара салым акчаларын кертергә, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (территорядәге үләннәрне чабу, килешү буенча эш һәм күрсәтелгән хезмәтләрне түләү)

2) Автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү, юлларны кардан чистарту, үлән чабу, юлга таш җәю);

3) Алга торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау (лампалар сатып алу һәм алыштыру)

3. Әлеге карарны Саклаубаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина